СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл жирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**28 сентябрь 2018ел** **№59**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Наласа авыл жирлеге территориясендә жирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «жирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, Наласа авыл жирлеге башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 12 номерлы "Референдум үткәрүне оештыру турында" карары нигезендә Наласа авыл жирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Наласа авыл жирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләргә.
2. Жирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда Наласа авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, балачак инвалидларыннан тыш, алар өчен түләүләр күләме 150 сум тәшкил итә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

1. Күмү урыннарын карап тоту:

- Наласа авылы зираты коймасын ремонтлау һәм зиратның тирә-ягын төзекләндерү эшләрен тәгәлләү.

2. Жирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- 2 данә мотопомп сатып алу;

- 2 данә янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Наласа авылында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- Урта Бирәзә авылында кече архитектура формаларын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү;

- Наласа авылында чишмәне төзекләндерү, материаллар алу һәм ремонтлау.

4. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- җирлек торак пунктлары чикләрендә юл-урам челтәренең юл полотносын чокырлар ремонтлау.

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов ур., 64 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Брәзә авылы, Татарстан ур., 90 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова